# ҮЗӘКТӘ — КЕШЕЛӘРНЕ ЯРАТУ

Елларны — еллар, заманнарны заманнар алыштыра. Заманнар белән бергә кешеләр дә үзгәрә. Борын-борыннан ук гадәткә кергәнчә, өлкән буын еш кына яшьләрнең кимчелекле якларын күзәтә, үз яшьлекләре белән чагыштыра. Әмма... Яшьләрнең өлкәннәрне кабатламавы кимчелек түгел ләбаса, ул — алгарыш. Такташ әйтмешли, «һәр заманның үзенә күрәсе» булса да, яхшылык барыбер күбрәк дип ышанасы килә. Бүгенге яшьләр тормышта үз кыйблаларын эзли, һөнәр үзләштерә, ярата, гаилә кора. Тик «ай киткән, ел киткән, энә буе җир киткән» батыр хәлендә түгел алар, компьютерлар, мобиль телефоннар, берсеннән-берсе кәттәрәк гаджетлар, үз максатларына барганда, төп таянычларына, адымнарын тизләтүче алыштыргысыз юлдашларына әверелгән. Әдәбият дөньясына беренче адымнарын ясаучы яшь каләм ияләренең әсәрләрендә дә алар, төп герой ук булмаса да, мөһим персонажлар дәрәҗәсендә дияр идем. Әмма бу шул ук вакытта авторның да, аның төп геройларының да дөньядагы урынын кечерәйтми, йөрәкләрендәге тере хисләрне сүрелдерми.

Яшь язучы Алмаз Мансуровның әсәрләрен укыгач, миндә шундый фикерләр туды. Алмаз — шәһәрдә туып үскән егет. Шуңа да ул тасвирлаган вакыйгалар күбесенчә шәһәр урамнарында, автобус тукталышларында, биек-биек йортлар эчендә бара. Алай да төп герой табигатьтән аерылмаган, аның күңел түрендә ландышлар чәчәк ата. Әйтик, аның «Барлык ландышлар да чәчәк атмый» дигән хикәясен укыганнан соң, ихтыярсыз шундый нәтиҗә ясыйсың. Төп герой тукталышта

сөйгән кызын көтә. Шул арада әйләнә-тирәне күзәтә, сатлык мәхәббәт корбаннарын да очрата, уйлана. Юк, ул көрәшкә чыкмый, конфликтка керми, бары тик бу дөньяның төрле төсләрдән торганлыгын күрә, чагыштырып карый. Ә менә «Җаннар кавышкан бермәлне» дигән хыялый хикәясендәге герой — Рәхим — дөньяны ямьләргә, кулыннан килгәнчә, кешеләргә ярдәм итәргә омтыла. Күбәләк рәвешенә кереп булса да. Антуан де Сент-Экзюпериның нәни принцы кебек үк, автор дөньяны игелекле, нурлы, кешелекле итеп күрергә тели.

Гомумән, Алмазның һәр хикәясендә кешеләрне ярату, күңел җылылыгы, хәтта балалык самимилеге бар. Бу хикәяләрне укыганнан соң, мин яшьләрдә тискәре сыйфатлар да булуына ышанмый башладым. Хәтта «Көтелмәгән һөҗүм» дигән хикәясе, шактый шомлы сурәтләр белән башланып китеп, эчкә шик-шөбһә йөгертсә дә, күңелле генә төгәлләнеп куя.

Алмаз үз милләтен эчкерсез ярата, аның бүгенгесе, киләчәге өчен борчыла. «Дога» хикәясендә төрле милләтләр арасына чөй какмыйча гына, аларның шулай да бер-берсеннән нык аерылып торуына басым ясый. Катнаш гаилә коруларның ахыр чиктә барыбер күңел фаҗигасенә китерүен ачык тормыш мисаллары белән дәлилләп күрсәтә.

«Үзем гаепле» повесте аерым игътибарга лаек. Яшүсмерлек максимальлеге, ахырын күзалламыйча, ялган мәхәббәткә тартылу, әти-әни белән капма-каршылыкның төзәтеп булмастай хаталарга китерүен автор зур осталык белән тасвирлый. Яшь егетнең чуалган язмышы үрмәкүч ятьмәсе белән тәңгәлләштерелә — гаҗәп!

Китап үзе дә яшүсмерләргә адресланган. Алмазның үзе кебек үк эчкерсез саф хисле, тормышта үз урынын табып, игелекле гамәлләр кылып яшәргә омтылучы егет-кызлар, һичшиксез, анда үзләрен күрер дип ышанасы килә.

*Фәйрүзә Мөслимова,*
шагыйрә

# Дога

Наташа аяк очларына гына басып килгән җирдән бүлмә уртасында тукталып калды. Урын өстендә яткан каенанасына тагын бер караш ташлап, авыр сулады да тәрәзә янына барып басты.

Җил ияртеп алып килгән соры болытларга сокланып карады ул. Алар бөтен күк йөзен каплап алганнар да ялга туктаган юлчылардай арып, салынып торалар. Пыскак яңгыр күңелләргә моң сеңдереп ява да ява. Бар дөньяны сагыш пәрдәсенә төрергә, үз ихтыярына буйсындырырга тели диярсең.

Шуңа күрәдер йорт каршындагы карт миләш тә, моңаеп, башын игән, юешләнеп сыгылып төшкән. Ә теге койма буендагы күгәрчен нигә бөрешеп утыра дип уйлыйсыз?

«Хәзер өеңә керәбез» дигән сыман тәрәзәгә шыбыршыбыр коелучы яңгыр тамчылары пыяла тузанында түгел, ә күңеле түрендә ямьсез эзләр калдыралар төсле тоелды Наташага.

— Нишләргә соң?.. Нишләргә?..

Инде ничә көннәр буе шушы сорау аның күңелен бимазалый. Нишләргә соң? Белми шул Наташа. Белсә, каенанасын савыктыру, һич югы, хәлен җиңеләйтү өчен, кулыннан килгәннең барысын да эшләгән булыр иде.

Чарасызлыктан, борылып, кабат бүлмә эченә күз салды ул. Нәрсәдер эзләгәндәй, диварларны, өй эчендәге җиһазларны җентекләп карап чыкты. Икеләнеп

торгандай итте дә, кабаланып, каршы як почмакка юнәлде.

Игътибарын стенага беркетелгән изге сурәткә юнәлтеп, бертын басып торганнан соң, ул авыз эченнән нидер пышылдап, берничә кат чукынып алды. Сурәт өстеннән кара япманы, салдырып, читкә ыргытты. Почмакка карап, идәнгә тезләнде.

Тынлыкны сискәндереп, бүлмәгә ялвару сүзләре таралды.

— Боже… — диеп пышылдады Наташа кайдандыр эчтән ургылып чыккан җан авазы белән: — Боже, помоги! Исцели мать!

Аның күзләре дымланды. Битләре буйлап тәгәрәп төшкән күз яшьләре белән күңеленнән изгелек суырылып чыккандай булды. Ул бар күңелен догага салды. Урын өстендә ятучы карчыкка саулык-сәламәтлек теләде. Ходайдан аның гомерен озайтуны сорады. Наташаның борчулардан агарынган йөзенә нур кунды, ә яргаланып беткән иреннәре туктаусыз дога сүзләрен кабатлады.

Кинәт зәгыйфь кенә, ләкин йомшак тавыш ишетелде. Ул акрын гына агылган бер көй сыман сузылып-сузылып яңгырады.

— Наилә, кызым…

Тавыш, куркып кына диварларга сарыла-сарыла, Наташа утырган почмакка үрмәләде. Ят телдәге догадан, изге сүзләрдән бераз тайчынды булса кирәк, шул авазга ияреп, бүлмә эчендә эреде.

Наташа аны бөтенләй ишетмәде. Чөнки күңеле белән, бу гөнаһлы җирдән аерылып, күккә күтәрелгән, изгеләр дөньясының ишеген шакыган иде инде. Ул бары тик хыяллары, уйлары белән ялгызы калган. Аның өчен күп нәрсә әһәмиятен югалткандай тоелды. Әйе, әйе, чөнки бөек Аллаһ бар. Бу, һичшиксез, шу-

лай. Ул — безгә гомер бирүче дә, алучы да. Һәм ул мәрхәмәтле булачак.

Тавыш кабатланды.

— Кызым...

Наташаның зиһене ачылып киткәндәй булды. Каенанасы эндәшә икән ләбаса. Тик ул ашыкмады. Иң элек, бар күңелен биреп, доганы тәмамлады:

— Господи, мы чтим и служим тебе верой и правдой. Прошу тебя, помоги!

Теләкләрен эчтән генә кат-кат кабатлап, озак кына чукынды да, башындагы кара яулыгының бер чите белән күз яшьләрен сөрткәләп, тиз генә урыныннан торды. Изге сурәтне каплап куйганнан соң, карчык янына ашыкты.

— Уяндыңмы, әнкәй? Что нибудь надо?

— Авызым кипте, килен. Чәй эчәсе иде...

— Хәзер, әнкәй! Хәзер...

Наташа, бөтен шартын китереп, чәй хәстәрләргә кереште. Бөтнек, мәтрүшкә, карлыган яфраклары белән тәмләп пешерде. Файдасы тимәсме дип, чынаякка калын гына лимон кисәге дә салырга онытмады.

— Менә, әнкәй...

— Бисмиләһи-ир-рахмән-ир-рахи-им.

Карчык, күтәрелеп, төсен җуйган иреннәрен чокырның читенә тидерде. Бер йотым чәй йотты да башын яңадан мендәргә салды.

Хәле юк иде шул аның, хәле.

Наташа чынаякны якындагы өстәлгә куйды. Сөйләнә-сөйләнә, каенанасының урын-җирләрен рәтләде, мендәрен җайлады:

— Менә күрерсең, әнкәй, тиздән терелерсең. Алай борчылма син, тынычлап ял ит. Нәрсә кирәк булса да читенсенмә, сора. Әлегә берни дә кирәкмиме? Ещё что нибудь надо?